**Нәниләр төркеме өчен төзелгән эш программасына аннотация**

Программа түбәндәге дәүләт документларына нигезләнеп язылды:

*Федераль дәрәҗәдә:*

- “Закон об образовании вРоссийской Федерации” (Принят 29 декабря 2012года № 273-ФЗ); -“Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима работы дошкольных организациях (Постановление от 15 мая 2013 года № 26 “Об утверждении СанПиН 2.4.1.3049-13);
- Приказ Минобразования Российской Федерации “Об утверждении Федерального государственного образовательного стандарта дошкольного образования” от 17.10.2013 № 1155;

*Региональ дәрәҗәдә:*

- “Закон РТ № 44 от 28.07.2004г. “О государственных языках РТ и других языках в РТ”.

Төркемдә белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге түбәндәге программаларга яраклаштырып төзелгән:

- Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү Программасы “От рождения до школы» (под редакцией Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой Москва «Мозаика-Синтез», 2010;, .
- Эш программасы түбәндәге норматив документларга таянып төзелгән:

Җирле дәрәҗәдә:

15 нче номерлы “Алсу” балалар бакчасы уставы

**Эш программасының төп фикере** - укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;

*Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;

**Программаның эчтәлеге**

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына, Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, Н.Е.Вераксы, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендәге ”Туганнан мәктәпкә кадәр”төп гомуми мәктәпкәчә яшьтә белем бирү программасына һәм 15 нче номерлы “Алсу” балалар бакчасының белем һәм тәрбия бирү программасына , балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде. Программа белем бирү процессын эшкә ашыруны өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеген, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген үз эченә алган ике төп оештыручы модель ярдәмендә тәэмин итә; 1.5 яшьтән 2.5 яшькә кадәр булган балаларга белем биргәндә яшь үзенчәлекләренә тәңгәл килерлек укыту моделен күздә тота.

**Программа буенча түбәндәге максатлар куелды:**

-һәр баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яклы үсеш алуы турында кайгырту;

- балаларның аралашучан, игелекле, кызыксынучан, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;

- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;

- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлеген күтәрү максатыннан аларны интеграцияләү.

**Программаның төп бурычлары :**

-балаларның сәламәтлеген ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше алып баруга этәрү, физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту;

-балаларда әйләнә –тирә дөньяга карата гуманлы караш үстерү, туган илне, туган телне яратырга этәрү, сөйләм культурасы һәм кешеләргә мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү;

-балаларда иҗади сәнгатькә, матур әдәбиятка карата кызыксыну уяту.

Бу максатлар бала эшчәнлегенең (уен,аралашу, хезмәт, танып-белү, иҗади, уку) төрле процессларында тормышка ашырыла.

Эш программасы системалылык һәм эзлеклелек, фәннилек, аңлаешлылык принципларын истә тотып төзелде.

# Нәниләр төркеме өчен төзелгән эш программасына аннотация